| | | |
|---|---|---|
| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 20 июль г.Казань № 697

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт үтүче затларга бер тапкыр акчалата түләүне гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2022 ел, 11 июль, 663 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт үтүче затларга бер тапкыр акчалата түләүне гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт үтүче затларга бер тапкыр акчалата түләүне гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2022 ел, 11 июль, 663 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт үтүче затларга бер тапкыр акчалата түләүне гамәлгә ашыру тәртибенә, 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«4. Бер тапкыр бирелә торган түләүне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты, контракт буенча хәрби хезмәткә сайлап алу пункты (1 разряд, Казан шәһәре) белән берлектә, бу Тәртипнең 2 нче кушымтасында бирелгән форма буенча шәхси счетларга акча күчерү өчен Татарстан Республикасында

төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт үтүче затлар исемлеген Министрлыкка кертә:

60,0 мең сум күләмендә – гариза бирүче хәрби хезмәт итүгә хәрби часть исемлекләренә кертелгәннән соң, әлеге исемлекләр Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты тарафыннан һәр дүшәмбе сәгать 10 га кадәр Министрлыкка бирелеп, атна саен 15шәр мең сум күләмендә;

200,0 мең сум күләмендә – Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы һәм Украина территорияләрендә махсус хәрби операциядә катнашу өчен Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннары Россия Федерациясенең дәүләт чиген чыкканнан соң.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин